ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

“Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында” 1994 елның 19 июлендәге 2180-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы икенче өлешендә (2008 елның 22 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994, № 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 7 – 8; 2003, № 9 (II өлеш); 2008, № 1; 2012, № 5 (I өлеш) “Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасы яисә” сүзләрен “Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары һәм” сүзләренә алмаштырырга.

## 2 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^{3}$ статьясындагы 2 пунктында (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) “, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеш программаларында” сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

“Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында” 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы икенче өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; 2003, № 6; 2005, № 7 – 8; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2012, № 5 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш) “Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасы яисә” сүзләрен “Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары һәм” сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары турында” 2004 елның 15 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы җиденче абзацында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш) “Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программаларын” сүзләрен “озак сроклы чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен” сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында” 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) бишенче абзацта “, шулай ук Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программалары проектларын” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы абзац өстәргә:
“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы стратегик планлаштыру документларын эшләү һәм төзәтү тәртибен билгели һәм мондый документларны раслый (хуплый);”;

3) алтынчы – унҗиденче абзацларны тәңгәл рәвештә җиденче – унсигезенче абзацлар дип санарга;

4) алтынчы абзацта “һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программалары үтәлеше турындагы хисапларны” сүзләрен “, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре хакындагы еллык хисапларны, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турындагы җыелма еллык докладны,

Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы үтәлеше барышы хакындагы еллык хисапларны” сүзләренә алмаштырырга.

**6 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5, № 10) “Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программалары,” сүзләрен төшереп калдырырга.

**7 статья**

“Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында” 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 2 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9; 2012 № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш) “Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең озак сроклы программалары” сүзләрен “Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары” сүзләренә алмаштырырга.

**8 статья**

“Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы $3^2$ өлешенең 5 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**9 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге турында” 2013 елның 15 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта “Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программалары проектлары” сүзләрен “Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары проектлары” сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 пунктта “Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программаларын” сүзләрен “Татарстан Республикасы дәүләт программаларын” сүзләренә алмаштырырга.

**10 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 05 март
№ 5-ТРЗ